**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт,Актаныш ав.,423740

Тел. (85552) 3-44-22, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Сайлап алу йомгаклары турында

«Дәүләт (муниципаль) милкендәге капиталь төзелеш объектларына капитал салуларга яисә күчемсез милек объектларын дәүләт (муниципаль) милкенә сатып алуга субсидияләр бирү яисә дәүләт (муниципаль) учреждениеләр булып тормаучы коммерциягә карамаган оешмаларга күчемсез милек объектларын сатып алу турында» тәртип нигезендә, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2017елның 16 августындагы ПР-132 номерлы карары белән расланган, 2022елның 15 апрелендә Актаныш муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр алу хокукына ия дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган коммерциягә карамаган оешмаларны сайлауда катнашуга конкурс заявкаларын карау буенча комиссия утырышы беркетмәсе нигезендә, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр алу хокукына ия түбәндәге юридик затлар сайлап алуны узган дип танырга:

Җирле ветераннар иҗтимагый оешмасы Актаныш районы, ИНН 1604002370 ОГРН 1031659010052, 6359077 (алты миллион өч йөз илле тугыз мең җитмеш җиде) сум 05 тиен, Актаныш муниципаль районы бюджеты хисабына.

2. Проектны гамәлгә ашыру максатларында җирле бюджеттан 6359077 (алты миллион өч йөз илле тугыз мең җитмеш җиде) сум 05 тиен күләмендә субсидия бүлеп бирергә.

3. Актаныш муниципаль районының финанс-бюджет палатасына:

1. Актаныш муниципаль районы бюджетының 01.01.2022 ел торышына караган калган акча хисабына 6 359 077,05 (алты миллион өч йөз илле тугыз мең җитмеш җиде )сум 05 тиен, 1941-1945 елларда Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 77 еллыгына багышланган чаралар оештыру һәм үткәрү өчен акча бүлеп бирергә.

2. Актаныш муниципаль районының Башкарма комитетына «Актаныш муниципаль районының 2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына бюджеты турында» Актаныш муниципаль районы Советының 2021 елның 14 декабрендәге 1303 номерлы карарына тиешле үзгәрешләр кертү хакында тәкъдимнәр кертергә.

4. Бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге башлыгы И.М.Шәеховага субсидияне күчерергә:

- Актаныш районы ветераннарының (пенсионерларның) җирле иҗтимагый оешмасы, ИНН 1604002370 ОГРН 1031659010052, 6359077 (алты миллион өч йөз илле тугыз мең җитмеш җиде) 05 тиен, Актаныш муниципаль районы бюджеты хисабына.

5.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары Л.Р.Сираевага йөкләргә.

Җитәкче Р.А. Ильясов